**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры**

**_______________ Э.Н. Фәттахов**

**«24» ________ 2016 ел**

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**татар төркемнәрендә белем алучы IX сыйныф укучыларына**
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН**
**төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы IX сыйныф укучыларына татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар**

ЯЗМА ӨЛЕШЕ

2017 нче елгы төп дәүләт имтиханының язма өлеше иҗади биремле изложение язу формасында үткәрелә. Төп дәүләт имтиханында укучының мөстәкыйль рәвештә мәгънәви бөтен, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерланган бирем башкаруына йөз тота. Әлеге төр изложение ярдәмендә укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре) тикшерелә.

Күрсәтмә вариант катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә төп дәүләт имтиханының төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә, әмма әлеге варианттагы биремнәр 2017 нче елдагы имтиханның барлык эчтәлек вариантларын да чагылдырмый. Тәкъдим ителгән варианттагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

**Эшне утәү өчен күрсәтмә**

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучыларга татар теленнән төп дәүләт имтиханының язма өлешен эшләү өчен, 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә.

Укучылар текстны 2 тапкыр тыңлыйлар. Беренче тапкыр тыңлаганнан соң, уйлану һәм караламада эшләү өчен, вакыт бирелә (5 минут). Текстны икенче тапкыр тыңлаганнан соң, изложение язу эше башлана. Изложение язу барышында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт бирелә.

Караламадагы язулар тикшерелми.

Язма эш махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Төп дәүләт имтиханы биремнәрен хаталарсыз башкарып, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

**Әкият**

Йоклар алдыннан Арслан исемле малай әнисенең әкиятләрен тыңларга бик ярата. Әкият тыңлаганда, йокыга китүен дә сизмичә кала, чөнки ул йоклаганда да, әкияттән аерылмый. Әкият аның төшендә яши башлый. Әнисенең тавышы инде тоныкк кына ишетелә.

Арслан йокы аралаш елмая. Бу әкият аңа таныш: кара урманда яшәүче Шүрәле турында сөйли аның әнисе. Әнә ул Арсланга кул болгый. Күзләре ялтырый, үзе йонлач, кул-аяклары исә агачның кәкре-бөкре ботаклары кебек. Бармаклары озын, чөнки ул урманда адашкан юлчыларны кытыклап уйнарга ярата.

– Син сабан туена кайтырга җыенасың икән, – ди Шүрәле Арсланга.

– Кайтам. Минем дә батыр буласым килә!

Арслан Шүрәледән курыкмый. Үз төшендә үзе нишләп курыксын? Шүрәле бит аның төшенә керде.

– Мин сине Батырлар иленә кертмим, – диде Шүрәле һәм, бармакларын сузып, Арсланга таба килә башлады.

Арслан чигенергә уйламады да.

– Анда минем бабайлар яшәгән. Ул – минем илем! – дип кычкырды малай.

– Бабаңның исемен беләсеңме соң?

– Белмичә. Аның исеме – Былтыр!

Шүрәлене ай күрде, кояш алды. Ул качты. Былтырның оныгыннан ничек качмасын?! Былтыр бит ул – кайчандыр аның бармакларын бүрәнә ярыгына кыстырган батыр. (172 сүз) *(Р. Зәйдулла буенча)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Арслан исемле малай әнисенең әкиятләрен тыңларга бик ярата. |
| **2** | Әнисе Арсланга Шүрәле турында сөйли. |
| **3** | Арслан төшендә Шүрәле белән сөйләшә |
| **4** | Шүрәле Арсланнан куркып кача |

**Язма эшне бәяләү критерийлары**

*1 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, **әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, **әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 0 |
| **ИК2** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК3** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **ИК4** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы текстан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 4 |
| | Укучы текстан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы башка текстан дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки** укучы биремдәге цитатаны я анның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | 10 |

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә**

*2 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, изложениенең күләмен исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш.

2 нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 100 һәм 100 сүздән күбрәк булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 50-99 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 50 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

## Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар

### ТЕЛДӘН ҖАВАП БИРҮ ӨЛЕШЕ

2017 нче елгы төп дәүләт имтиханын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән биремнәр 2017 нче елда имтихан үткәрү материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмый. 2017 нче елгы төп дәүләт имтиханында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге рус телендә урта гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен төп дәүләт имтиханына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә төп дәүләт имтиханы материалларының структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Күрсәтмә вариант материаллары чыгарылыш сыйныф укучыларында төп дәүләт имтиханына әзерлек осталыгын булдырачак.

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН төп дәүләт имтиханы**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен татар теленнән төп дәүләт имтиханының телдән җавап бирү өлеше 2 биремнән гыйбарәт.

**Беренче биремдә** күләме зур булмаган текстны кычкырып уку күз алдында тотыла. Әзерлек өчен 2 минут вакыт бирелә.

**Икенче биремдә** шартлы сораштыруда катнашырга тәкъдим ителә. Аудиоязмадан ишетелгән биш сорауга җавап бирергә кирәк.

**Өченче биремдә** тәкъдим ителгән фото турында сөйләү каралган. Әзерлек өчен 2 минут вакыт бирелә.

**Дүртенче биремдә**, планга нигезләнеп, аерым бер темага эзлекле монологик сөйләү күз алдында тотыла.

Төп дәүләт имтиханында катнашучы бер укучы бу биремнәрне 15 минут эчендә эшләргә тиеш. Җаваплар аудиоязмаларга теркәлеп бара. Биремне төгәл үтәргә, бирелгән темадан читләшмичә, тәкъдим ителгән план буенча ачык һәм аңлаешлы сөйләргә кирәк. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

**Өзекне сәнгатьле итеп кычкырып укыгыз. Әзерлек өчен сезгә – 2 минут, уку өчен 2 минут вакыт бирелә.**

*Мөхәммәт Мәһдиевнең*
*«Зур фикер» язмасыннан кыскартып алынган өзек*

Искәндәрнең һәрвакытта да сораулары була. Әйтерсең ул гел сорау гына уйлап йөри.

Бөек Ватан сугышында җиңүгә утыз ел тулган көн иде. Искәндәрнең ул көнне дә сораулары бик күп булды.

– Сугышны ник башладылар? Гитлер чыннан да үлгәнме? Жуковның ничә ордены бар? Дөньяда иң күп орденлы кеше кем?

Бу сорауларның барысына да җавап биреп бетерү мөмкин түгел иде, ләкин сорауларның исәбе-хисабы булмады.

Көннәрдән бер көнне ул, кич белән урынына яткач, караватына әтисен чакырып алды. Әтисе юрган астына кереп яткач, Искәндәр аның колагына сер сөйли башлады:

– Әти, беләсеңме нәрсә? Мин бер әйбер уйлап таптым. Тик кешегә әйтмә.

Ул бераз дәшми торды.

– Болай була: мин Илшат, Илюша, Инесса, Оля белән дус. Ә аларның тагы үз дуслары бар. Ә ул дусларның тагын дуслары бар. Шулай булгач, Җир шарындагы бөтен кеше дус булып чыга?

– Әйе, шулай булып чыга.

– Алайса, кешеләр ник сугышалар? Бөтен кеше дус булгач...

Әтисе бу сорауга җавап биреп бетергәнче, малай йокыга талган иде.

2 **Сораштыруда катнашып, куелган сорауларга җавап бирегез. Сезгә 5 сорау бирелә. Һәр сорауга җавапны 40 секундта әйтеп бетерергә тырышыгыз. Тулы җавап бирегез.**

1. Кайсы халыкларның милли бәйрәмнәре турында ишеткәнегез бар?
2. Кайсы милли бәйрәмдә үзегезнең катнашканыгыз бар?
3. Бу бәйрәм елның кайсы вакытында уза?
4. Әлеге милли бәйрәм ничек уза?
5. Милли бәйрәмнәр ни өчен кирәк?

3 **Рәсемдә нәрсәләр күрәсез? Шул турыда сөйләгез. Сезгә әзерлек өчен – 2 минут, сөйләү өчен 2 минут вакыт бирелә.**

4 **Татар халкының күренекле шәхесе турында сөйләгез. Әзерлек өчен сезгә 2 минут, сөйләү өчен 2 минут вакыт бирелә.**

Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын:

Ни өчен аны күренекле шәхесләр исемлегенә кертәләр?

Әлеге шәхеснең нинди уңышларын беләсез?

Сезгә бу шәхеснең кайсы сыйфатлары ошый?

Бүгенге көндә әлеге шәхеснең истәлеге ничек саклана?

**Татар теле буенча төп дәүләт имтиханының телдән җавап бирү өлешен бәяләү системасы**

**1 нче бирем** (максимум – 12 балл)

| № | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сөйләмнең сәнгатьлелеге | | | сөйләм сәнгатьле укылган | сөйләм сәнгатьле укылмаган |
| 2 | Тел нормаларының үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |
| 3 | Сүзләрне дөрес уку | | | хата юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| 4 | Орфоэпик нормаларның үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |
| 5 | Интонациянең саклануы (пунктуацион бирелешкә тәңгәл килү) | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |
| 6 | Уку тизлеге | | | коммуникатив бурычны үтәүгә туры килә | коммуникатив бурычны үтәүгә туры килми |

**2 нче бирем (максимум – 25 балл)**

| № | Бәяләү критерийлары | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|
| Һәр сорауга җавап түбәндәгеләрдән чыгып бәяләнә | | | | |
| 1 | Мәгънәви бөтенлек, сөйләмнең эзлеклелеге | логик хаталар юк, сөйләм эзлекле | 1 логик хата бар | логик хаталар 1дән күбрәк, сөйләм эзлекле түгел, коммуникатив бурыч авырлык белән генә үтәлгән |
| 2 | Орфоэпик нормаларның үтәлеше | | хаталар юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| 3 | Тел нормаларының үтәлеше | | хаталар юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| 4 | Сөйләм хаталарының булуы | | хаталар юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| Бер сорау өчен иң югары балл - 5 | | | | |

**3 нче бирем (максимум – 14 балл)**

| № | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Коммуникатив бурычның үтәлеше* | Бирем тулысынча үтәлгән: тема тулысынча ачылган; аралашу ситуациясенә ярашлы иҗтимагый һәм мәдәни мәгълүматлар файдаланылган | Бирем үтәлгән: аралашу максатына ирешелгән; әмма тема тулысынча ачылмаган; аралашу ситуациясенә ярашлы иҗтимагый һәм мәдәни мәгълүматлар нигездә файдаланылган | Бирем өлешчә үтәлгән: аралашу максатына тулысынча ирешелмәгән; тема бик аз ачылган; аралашу ситуациясенә ярашлы иҗтимагый һәм мәдәни мәгълүматлар аз файдаланылган. | Коммуникатив бурыч үтәлмәгән |
| 2 | Мәгънәви бөтенлек, сөйләмнең эзлеклелеге | | логик хаталар юк, сөйләм эзлекле | 1 логик хата бар | логик хаталар 1 дән күп, сөйләм эзлекле түгел, коммуникатив бурыч авырлык белән генә үтәлә |
| 3 | Сөйләмдә сүз байлыгы чагылышы, соралган мәгълүматның төгәл бирелеше, грамматик конструкцияләрнең төзеклеге | | сөйләм төгәл, сүз байлыгы җитәрлек, төрле грамматик конструкцияләр кулланылган | Сөйләмдә тайпылышлар бар һәм/яки бертөрле грамматик конструкцияләр кулланылган | сүз байлыгы түбән, бертөрле грамматик конструкцияләр кулланылган |
| 4 | Орфоэпик нормаларның үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |
| 5 | Сөйләм хаталарының булуы | | | хата юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| 6 | Тел нормаларының үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |

**4 нче бирем (максимум – 14 балл)**

| № | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Коммуникатив бурычның үтәлеше* | Бирем тулысынча үтәлгән: тема тулысынча ачылган; эчтәлек биремдәге барлык аспектларны тулы һәм төгәл чагылдыра | Бирем үтәлгән: аралашу максатына ирешелгән; әмма 2 аспект ачылмаган (калганнары тулысынча ачылган) ЯКИ барлык аспектлар да тулысынча ачылмаган | Бирем өлешчә үтәлгән: аралашу максатына тулысынча ирешелмәгән; тема бик аз ачылган; 2 аспект ачылмаган (калганнары тулысынча ачылган) ЯКИ барлык аспектлар да тулысынча ачылмаган | эчтәлекнең 3 яки күбрәк аспекты ачылмаган |
| 2 | Мәгънәви бөтенлек, сөйләмнең эзлеклелеге | | логик хаталар юк, сөйләм эзлекле | 1 логик хата бар | логик хаталар 1 дән күп, сөйләм эзлекле түгел, коммуникатив бурыч авырлык белән генә үтәлә |
| 3 | Сөйләмдә сүз байлыгы чагылышы, соралган мәгълүматның төгәл бирелеше, грамматик конструкцияләрнең төзеклеге | | сөйләм төгәл, сүз байлыгы җитәрлек, төрле грамматик конструкцияләр кулланылган | Сөйләмдә тайпылышлар бар һәм/яки бертөрле грамматик конструкцияләр кулланылган | сүз байлыгы түбән, бертөрле грамматик конструкцияләр кулланылган |
| 4 | Орфоэпик нормаларның үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |
| 5 | Сөйләм хаталарының булуы | | | хата юк | 1 яки күбрәк хата бар |
| 6 | Тел нормаларының үтәлеше | хаталар юк | 1 хата бар | 2 -3 хата бар | хаталар саны 4 яки күбрәк |

**Тест эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-42 балл – «2» ле билгесе;

43-54 балл – «3» ле билгесе;

55-66 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: телдән сөйләм биремнәре өчен 32 дән кимрәк балл җыйса, «3» ле билгесе куела.

67-85 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: телдән сөйләм өчен 38 дән кимрәк балл җыйса, «4» ле билгесе куела.